**Тема: “Әдәп һәм оят- әхлакның нигезе”**

**Максат:**

1.Укучыларда ояла белү, тыйнаклык, кылган гамәлләре өчен җаваплылык хисен тәрбияләү.
2. Кешеләргә карата изгелек, рәхимлелек, мәхәббәт, ихтирам хисе тәрбияләү.
3. Укучыларның үз фикерләрен ачык, матур итеп башкаларга җиткерә, дәлилләп күрсәтә белүләренә ирешү.

**Дәреснең көтелгән нәтиҗәсе:**

- Һәрбер эш өчен кешеләр һәм Аллаһ каршында җавап бирәсен аңлау.
- Яхшылык та яманлык та үзеңә кире кайтасы турында төшенү.
- Оялчанлык- бөтен начарлыктан тыела белү икәнен белү.

**Эпиграф:**

- *“Ояла белгән кеше яхшылыктан башка бернәрсә эшли белми” /Хәдис/*

**Дәрес барышы**

**I. Уку мәсьәләсен кую.**

- Кечкенә генә хикәяне тыңлагыз, шуннан чыгып, бүгенге дәреснең темасын үзегез әйтеп бирегез:

*Бервакыт изге күңелле һәм кабәхәт кешеләрнең Оятлары очрашканнар. Икенчесе хуҗасыннан бик зарланып:”Матур китапларны да аңа биргәләдем, яхшы кешеләр белән дә очраштырдым, файдасыз- үзен генә ярата. Бөтен кешеләрдән алда, бай, өстен булу- аның яшәү мәгънәсе. Горурлык, мин-минлек хуҗамны буып алды. Миңа, Оятка, күңелендә урын калмады инде” дигән.*
*Изге кешенең Ояты: “Ә без аны кызык итик- карарбыз нәрсә булыр!”Бераз пышылдашып, ике кешенең Оятлары хуҗаларына кире кайтканнар.*
*Иртән кабәхәт кеше уянуы белән:*
*- Туйдырды инде мине хатыным!”дип уйлады.*
*- Ничек туйдырдым? Ни гаебем бар: ашарга пөшерәм, җыештырам, эшкә барам!- диде хатыны.*
*- Бу карт сыер мин уйлаганны каян белгән микән?- дип уйлау белән хатыны:*
*- Мин карт сыер мени?*
*Кабәхәтнең башы авырта башлый. Начальникка шалтыратып баллы тавыш белән:*
*- Хәерле иртә- дип әйтсә дә, эчтән:”Бу карт кәҗә пенсиягә кайчан китәр микән?”- дип уйлап куйды.*
*- Мин карт кәҗә мени?Эшкә килмә- уволен!*
*Шулай итеп кабәхәт кеше үзенең уйлары бөтен кешегә шулук мизгелдә билгеле булганын аңлый. Уйламыйча да булмый бит... Ул тыштан елмаерга,*

*ә өчтән дусларына ярлы булуын, күршеләренә уңышсызлык теләргә ияләнгән иде.*

*Хатыны ташлап киткән, аның белән аралашырга, эш итәргә теләгән кеше юк инде хәзер. Бөтенесе дә аңа:"Ай- хай, Оятың юк икән синең!"- дип әйтә башлаганнар. "Ни эшләргә? Кайда соң минем Оятым?"- дигәндә генә, кабәхәтнең Ояты: "Мин хәрвакыт яныңда идем- тик син мине тыңламадың. Хәзер синең йөрәгең әрни- үзең рәнҗеткән кешеләрнең хәлләрен аңлагач кына мине ишеттең."*

*- Миңа хәзер ни эшләргә?*

*- Бөтен кешегә яхшылык теләргә өйрән- аннары очрашырбыз!*

*Авыр булды оятсыз кешегә: үзенең кабәхәтлеге кире кайтып бетмичә, ул яңадан башкаларны кызыганырга, аларга ярдәм итәргә өйрәнмичә, үзенең начар теләкләрен, уйларын үзгәртмичә, кайтмады аңа Оят.*

*Ялгызлык, кеше нәфрәте аны үз уйларын, хисләрен күзәтергә, контрольдә тотарга өйрәтте. Үзенең сабыр, саф күңелле кешегә әйләнүен сизми дә калды. Ояты да кире кайтты.*

**II. Дәреснең темасын ачыклау.**

Димәк, бүгенге дәреснең темасы... ("Әдәп һәм оят- әхлакның нигезе").

**III.Уку мәсьәләсен чишү.**

- Нинди кеше оятсыз була?
- Нинди кеше оялчан була?

1. **Төркемнәрдә эшләү.**

- Төркемнәрдә эшләп алыйк.

**1нче бирем "*Ике исем*"**

- Текстка ике исем кушыгыз:
  - беренчесендә аның темасы күренсен *(Ояла белү).*
  - икенчесендә- текстның төп фикере ачыклансын (*Оятсызлык кешене бәхетсез итә).*
- Һәр төркем үз җаваплары белән таныштыра (1, 2 төркем).

**2нче бирем *Үгет- нәсыйхәт.***

- Хикәядәге кабәхәт кешегә нинди үгет- нәсыйхәт, киңәшләр бирер идегез? (Җаваплар):

- Үзеңне кешеләрдән өстен күрмә, аларны хөрмәт ит.
- Оятсызлык эшләгәндә, син рәнҗеткән кеше урынына үзеңне куеп кара.
- Уйлар, теләкләр саф, чиста, көрсез булсын- фәрештәләр аларны язып баралар- җавап бирәсе булыр.
- Кешеләргә яхшылык кына telә, эшлә- ул кире кайтыр.
- Начарлык эшләмә- чөнки ул да кире кайтыр.

- Димәк, оятсыз кеше башкаларны гына түгел- үзен дә рәнҗетә, бәхетсез итә.

- Һәр төркем үз җаваплары белән таныштыра (1, 2 төркем).

**3нче бирем** ***Уен "Мин башлыйм, син дәвам ит"*** *(*мәкальләрне тәрбияче башлый, укучылар дәвам итә).

- Балалар! Хәзер уен уйнап алыйк! Мәкальләрне мин башлыйм- сез дәвам итәрсез. Җавапны хор белән- башта-беренче, аннары- икенче төркем бирә:

- Курку булмаган җирдә әдәп ... *булмый.*
- Яңгырдан соң кояш бар- алдаудан соң ... *оят бар.*
- Ялганчы калыр оятка, гадел җитәр... *бәхеткә.*
- Хәя (оят) барда ... *иман бар.*
- Алладан курыкмаган- бәндәдән ... *оялмас.*
- Әдәпленең күлмәге сәдәпле, үзе матур ... *гадәтле.*
- Оялмаган кеше өчен оятлының йөзе ... *кызарыр.*
- Үгет бездән, әдәп белү ... *үзеңнән.*
- Үзе әдәпсез, киеме ... *сәдәпсез.*
- Һәр кешенең ояты үзе ... *төсле була.*
- Әдәмне әдәм иткән ... *әдәп.*
- Әдәпле кеше солтан, әдәпсезнең бите ... *олтан.*
- Әдәпленең күлмәге сәдәпле, үзе матур ... *гадәтле.*
- Әдәпсез алда мактар, артта .. *яманлар*
- Холкы бозык кешенең фикере дә ... *бозык була.*
- Төкәнмәс хәзинәм булганчы оялмас ... *йөзем булсын.*
- Оят булмаган җиргә ... *бәла* килә.
- Оят юкта ... *иман юк.*
- Оят үлемнән ... *каты.*
- Оятның теше булмаса да ... *кимерә.*
- Оятсызлык йөз ... *ерта.*
- Оятсызлык төтен шикелле — күзгә ... *керә.*

- Кайсы мәкальләр без укыган хикәягә бигрәк туры килә? (Әдәмне әдәм иткән ... *әдәп.*Алладан курыкмаган- бәндәдән ... *оялмас.* Оят юкта ... *иман юк).*

**4 бирем** ***"Кеше хәленә керергә өйрәник"***

- Кабәхәт кешегә рәнҗегән хатыны һәм начальникның үпкә уй- сүзләрең алар булып әйтеп карагыз. /Җаваплар/:

(Хатыны: "Ий, гомер буе бергә яшәдек: балаларыбызны үстердем, аларны тәрбияләдем, көр юдым, өйләр җыештырдым, бакчада бергә яшелчә үстердек, эшкә бардым, сиңа тугъры булдым, йөзеңә кызыллык китермәдем- ә мин сиңа "сыер" дидең;.

Начальнигы: "Яхшы эшкә үзем урнаштырдым, сорасаң- кирәк чакта җибәрдем, зарплатаны арттырдым...")

- Төркемнәрдәге эшне тәмамладык. Алар үзләрен яхшы белемнәрен күрсәттеләр.

**<u>2. Бөтен класс белән эш.</u>**

**1) Танылган шәхесләргә сүз бирик:**

- *Ояла белгән кеше- хөрмәткә лаеклы кеше. /Б.Шоу/*
- *Кешеләрдән оялуга караганда үз- үзеңнән ояла белү яхшырак. /Л.Толстой/*
- *Оятын югалткан кешене үзен һәләк иткән дип белергә кирәк. /Ф.Бекон/*
- *Тумыштан оятсыз кеше оятсызлыгыннан төзәлмәс. /Цицерон/*

- Бу сүзләр турында үз фикерләрегезне әйтегез.

**2) Интернетка сәяхәт.**

- Дәрескә әзерләнгән вакытта Интенет сайтларына керми булмый. Ә анда бүгенге дәрес темасына төрле карашлар. Мәсъәлән, кайбер статьяларның исемләре:

- Оялудан ничек котылырга?

- Оятсызлык- беренче бәхет.

***Берәү яза:***

- *“Ояла белү сәләте югалуга таба бара. Бу заманда оялу, оялчанлык кирәкмәс сыйфатына әйләнеп бара шикелле. Нахаллык, оятсызлык хуплана”.*

- Чыннанда, оялчанлык кешеләрдә кимедеме, юкмы? Ни өчен? Үз фикерегезне әйтегез. (Кимеде, чөнки куп кешеләр Аллаһтан курыкмыйлар, кешедән оялмыйлар).

***Икенче берәү болай дип яза:***

- *“Оялчанлык бер җирдә дә, бер кем тарафыннан да хупланмый. Ул чирне дәваларга кирәк”.*

- Ояла белү чирме, әллә безгә кирәкле бер сыйфатмы? Ни өчен? Үз фикерегезне әйтегез. (Ояла белү бик кирәкле сыйфат, чөнки ояла белмәгән кеше хайванга әйләнә: аңа алдарга, үтерергә, кеше хакын ашарга да ярый...)

***Өченче фикер:***

- *“Балачагымда кибеттә “Сникерс” урлаган идем. Намусым 5 ел буена миңа тынычлык бирмәде, оятым белән 5 ел көрәшеп, ул (оят, намус) мине җиңде: шулук кибетнең шулук киштәсенә “Сникерсны” кире кайтарып куйдым”.*

- Сез шулай (алган әйберне куеп) эшли алыр идегезме, юкмы? - дигән сорауга <u>өчтән генә</u> җавапны эзләп карагыз...
- Өч фикернең кайсын дөрес дип уйлыйсыз? Ни өчен?

- Кайбер чакта балалар, “ялгыш”дип әйтер идек, кеше әйберсенә кызыгып аны урлыйлар. Бу хатаны тиз арада аңлаган, төзәткән кеше бик намуслы, көчле, бәхетле кеше.

***Тагын бер фикер:***

- *“Ә мин болайрак фикер йөртәм: оялчан булу- оятың, намусың булу. Киресенчә булганда- син оятсыз, нахал. Ә татар хатын –кызлар элек-электән тыйнак, оялчан булганннар шул. Ир- атлар оятсызлар белән вакыт уздыралар, ә оялчанраклары белән гомер итәләр. Әллә ялгышам микән?”*

- Кайсы фикер сезнең күңелегезгә якынрак? Ни өчен?
- Оялчанлык модада түгел шикелле тыелса да, оятсыз кызлардан “файдаланып”, егетләр гомер итәр өчен тәртипле, оялчан кызларны сайлыйлар икән.

**3) Хәдисләр.**

- Мөхәммәд Пәйгамбәрнең (с.г.в.) хәдисен укып, үз фикерләрегезне әйтегез. Мөхәммәд Пәйгамбәр (с.г.с) әйтә:
  - ***“Ояла белгән кеше яхшылыктан башка бернәрсә эшли белми”.***
  - ***“Кешеләрдән оялмаган, Аллаһыдан да оялмас”.***
  - ***“Оялчанлык- иманлы булудан”.***
  - ***“Оялмаган кеше теләгәнен эшләсен”.***
  - ***“Оялчанлык- бөтен начарлыктан тыела белү”.***

- Бу сүзләрне ничек аңлыйсыз? Фикерләрегезне исбатлагыз.

- Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) үзе искиткеч оялчан булган, безгә дә оялчанлык күрсәтергә тиеш дип әйтеп калдырган. Әгәр кеше эшләгән хата, гөнаһтан оялмаса, аны начар эшләрдән тыеп булмаячак.

Кешеләрнең оялуы ике төрле була: Аллаһыдан оялу, кешеләрдән оялу. Аллаһыдан оялу кешеләрдән оялудан өстен, чөнки Раббызбыдан оялу кешене явыз эшләрдән туктата. Ә Аллаһы Тәгаләдән оялмаган кеше җир йөзендә бөтен әшәкелекне, бозыкны кыла. Оят кешеләрдә була торган күркәм әхлакларның берсе булып санала, ул иманның камиллеген, ныклыгын күрсәтә. Тумыштан ук килә торган оялчанлыкка ия булучы кеше әхлакның иң югары дәрәҗәләренә күтәрелә, гөнаһ эшләүдән тыела, начар холыклардан саклана.

**4) Эпиграф белән эш.**

- *“Ояла белгән кеше яхшылыктан башка бернәрсә эшли белми”.*

- Бу сүзләрне бүгенге дәреснең эпиграфы итеп тактага яздык. Җөмләне хор белән кабатлыйк һәм үзебезнең йөрәкләребезгә гомер буена салыйк, беркайчанда онытмыйк. Хор белән укыйлар.

- <u>Җөмләне дәвам итеп карыйк</u>: “Ояла белгән кеше яхшылыктан башка бернәрсә эшли белми, чөңки...” (... чөңки ул Аллаһыдан, кешеләрдән, үзеннән- үзе оялып кешене рәнҗетүгә, алдауга, әдәпсезлеккә, урлауга, ялкаулыкка бармый).

**V. Рефлексия (Йомгаклау).**

**-** Дәреснең темасын искә тешерегез.

- Үзегез өчен нинди гыйбрәтләр алдыгыз? Фикерегезне исбатлагыз. *(Оятсызлык кешене бәхетсез итә, чөңки* һәрбер эш өчен кешеләр һәм Аллаһ каршында җавап бирәсе бар. Яхшылык та яманлык та үзеңә кире кайта).

- Үзегез өчен нинди нәтиҗә ясадыгыз**?** ***(“Ояла белгән кеше яхшылыктан башка бернәрсә эшли белми”,*** чөнки ул начарлык эшләргә кешеләрдән, Аллаһы Тәгаләдән ояла).

- Ояла белү, тыйнаклык һәм гаделлек – тәрбияле кеше өчен бик мөһим сыйфатлар. Тәкәбберлек, үзеңне өстен кую, урынсыз горурлык һич тә кабул ителми, чөнки кешеләрнең бер-берсе алдында өстенлеге юк, алар игелеклелек һәм зирәк акыллы булулары белән генә аерыла. Оятсызлык кешегә теләсә нинди гөнаһ кылырга юл ача, ә оялчанлык, киресенчә, аны бөтен начарлыктан, гөнаһтан тыя, чөңки әдәп һәм оят- әхлакның нигезе.

**VI. Өйгә эш:**

- Өй эшен вариантлап бирәбез:

1. “Ни өчен дустыңның оятсыз булуын теләмәс идең?” дигән темага җавап әзерләп килергә.
2. “Оялчан кешенең гадәтләре” дигән темага җавап әзерләп килергә.